ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/20

Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясе күләмен һәм гамәлгә кую тәртибен билгеләү турында

Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/13 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезнамәгә таянып, Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри үсешен стимуллаштыру максатыннан,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләрең хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен 20 000 сум күләмендә билгеләргә.

2. Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибен кушымтада каралганча расларга.

3. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2008 елның 13 декабрендәге «Физкультура һәм спорт юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую һәм күләмен билгеләү тәртибе турындагы Нигезнамәне раслау хакында» 36/8 санлы Карарын,

«Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 24 декабрьдәге 246-247 нчы саннарында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы «Физкультура һәм спорт юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премияләрен гамәлгә кую тәртибе турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 50/10 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2010 ел,11 июньдәге 109-111 нче саннарында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге «2008 елның 13 декабрендә Шәһәр Советының 36/8 санлы Карары белән расланган физкультура-спорт юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре педагогик хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премияләрен гамәлгә кую тәртибе турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 21/18 санлы Карарын «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 03 октябрьдәге 77 нче санында бастырылган.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының 27/20
санлы Карарына кушымта
08 ноябрь, 2018 ел

Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибе турында
НИГЕЗНАМӘ

1. Әлеге Нигезнамә Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен (алга таба – шәһәр Хакиме премиясе) гамәлгә кую тәртибен билгели.

2. Шәһәр Хакиме премиясе Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре тренер-укытучыларына, инструктор-методистларына һәм җитәкчеләренә узган календарь елында һөнәри эшчәнлекләрендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен бирелә.

3. Яр Чаллы шәһәре хакиме Премиясе шәһәр Хакиме Карары белән гамәлгә куела. Карарда премия саны күрсәтелә.

4. Шәһәр Хакиме премиясе - бер тапкыр бирелә торган түләү, ул ел саен Физкультурачылар көне (августның икенче шимбәсе) алдыннан башкарыла.

5. Шәһәр Хакиме Премиясенә кандидатларны Яр Чаллы шәһәре спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен бирү комиссиясе (алга таба – комиссия) түбәндәге материаллар нигезендә сайлап ала:

1) шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүчедән гариза, әлеге Нигезнамәнең 1 нче кушымтасында каралган тәртиптә;

2) кандидатны шәһәр Хакиме премиясен тәкъдим итү хакында коллектив утырышы беркетмәсеннән өземтә;

3) ирешкән нәтиҗәләрен, узган календарь елында дисциплинар җавалылыкка тартылуын (тартылмавын) күрсәтеп, шәһәр Хакиме премиясенә кандидатка характеристика;

4) белем турында диплом (дипломнар) күчермәсе (күчермәләре);

5) соңгы биш елда квалификация күтәрү хакында диплом (дипломнар) күчермәсе (күчермәләре);

6) хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

7) шәһәр Хакиме премиясен алырга алырга теләүченең узган уку елында тулы укыту-педагогик эш күләмен дәлилләүче тариф кәгазе яки боерык күчермәсе (педагогия хезмәткәрләре өчен);

8) узган календарь елында башкарылган эш хакында аналитик белешмә (хисап);

9) шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүченең шәхси

мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы хакында гаризасы, әлеге Нигезнамәнең 2 нче кушымтасында каралган тәртиптә;

10) соңгы өч елда муниципаль, региональ, республика, бөтенроссия дәрәҗәсендә бүләкләнү хакында документның (документларның) күчермәсе;

11) төрле дәрәҗәдәге фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда, смотрларда һәм башка һөнәри чараларда катнашуы турындагы документ (документлар) күчермәсе, басылып чыккан язма (язмалар) күчермәсе (булган очракта);

12) оештыру-хокукый формасына карамастан оешмалардан, массакүләм матбугат чараларынан бәяләмәләр, теләктәшлек итү хатлары (булган очракта);

13) шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче муниципаль учреждение җитәкчесе булганда, муниципаль учреждениенең Россия Федерациясе бюджет системасындагы бюджетларга салым, җыем һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау хакында белешмә;

14) шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче муниципаль учреждение җитәкчесе булганда, муниципаль учреждение хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бурыч булмау хакында белешмә.

Тәкъдим ителүче барлык материаллар да шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүченең эш бирүчесе тарафыннан раслана һәм агымдагы елның 15 июненнән 15 июленә кадәр комиссия секретаренә җибәрелә.

6. Комиссия, аның составы, шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүчеләрне сайлап алу критерийлары турында Нигезнамә Башкарма комитет карары белән раслана.

7. Шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче комиссия әгъзасы булган очракта, ул вакытлыча комиссиядә эшләүдән азат ителә.

8. Комиссия беркетмәсенә нигезләнеп, Яр Чаллы шәһәре Хакиме шәһәр Хакиме премиясен бирү турында карар кабул итә. Әлеге карар 3 эш көне эчендә шәһәр Хакиме премияләрен түләү өчен Башкарма комитет карары чыгару максатында Башкарма комитетка җибәрелә.

9. Шәһәр Хакиме премиясен түләү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чигендә башкарыла.

10. Шәһәр Хакиме премиясе лауреатлары премия бирелгән вакыттан алып өч ел узганнан соң гына яңа уңышларга ирешкән өчен шәһәр Хакиме премиясенә кабат тәкъдим ителергә мөмкин.

Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибе турында Нигезнамәгә
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең яшьләр сәясәте өлкәсендәге муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясе бирү комиссиясе рәисенә
___________________________________
(Рәиснең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Шәһәр Хакиме премиясен алу өчен гариза[1]

| | |
|---|---|
| Шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүченең фамилисе, исеме, атасының исеме (тулысынча) | |
| Вазыйфасы | |
| Муниципаль учреждение исеме[2] | |
| Муниципаль учреждениегә эшкә алу турында боерык саны һәм датасы | |
| Эш телефоны | |
| Кәрәзле телефон | |
| E-mail | |
| Шәһәр Хакиме премиясе лауреаты булганым бар[3] | |
| Сайлап алу конкурсы критерийлары нигезендә сайлап алу өчен каралган балларның максималь саны | |
| Сайлап алу конкурсы критерийлары нигезендә җыелган баллар саны[4] | |

Шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче _______________ (имза) _________________________________
(имзаның расшифровкасы)

Директор ______________________ ___________ _________________________
(муниципаль учреждение исеме) (имза) ( имзаның расшифровкасы)

м.у.

Дата _____ ____________ 20______ г.

---

[1] Гарзиа аңлаешлы итеп кулдан языла яйсә компьютерда җыела
[2] Муниципаль берәмлек Уставында күрсәтелгәнчә
[3] Шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче шәһәр Хакиме премиясе Лауреаты булган очракта (елы күрсәтелә)
[4] Шәһәр Хакиме премиясен алырга теләүче үз эшен конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары нигезендә бәяли

Яр Чаллы шәһәренең спорт юнәлешендә өстәмә белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре өчен Яр Чаллы шәһәре Хакиме премиясен гамәлгә кую тәртибе турында Нигезнамәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү

Мин________________________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме тулысынча )

Түбәндәге адрес буенча теркәлгән:
_____________________________________________________________________,
шәхесне раслаучы документ: __________, серия:______ номер:____________
бирелгән көне «______» ________________бирүче _____________________________
___________________________________________________________,
2006 елның 27 июлендә кабул ителгән 152-ФЗ санлы “Шәхси мәгълүматлар турында” Федераль законының 9 маддәсе (алга таба - 152-ФЗ санлы Закон) нигезендә, минем шәхси мәгълүматларны эшкәртергә, тормышымдагы фактлар һәм вакыйгалар хакындагы мәгълүматлар белән 152-ФЗ санлы Законның 3 маддәсендә каралган тәртиптә гамәлләр кылырга ризалык бирәм.

152-ФЗ санлы Закон таләпләре нигезендә эшкәртергә ризалык биргән шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән, паспорттагы мәгълүматлар, белем турында мәгълүматлар (уку йорты исеме, аны тәмамлау елы, белгечлек), җенес, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем, махсус исем, дәүләт бүләкләре (шул исәптән, бүләкләнү вакыты), башка бүләкләр белән бүләкләнү, элек эшләгән эш урыннары (гомуми эш стажын кертеп) хакында мәгълүматларны, 152-ФЗ санлы Законның 6 маддәсендә каралганча, мине шәһәр Хакиме премиясе белән бүләкләүгә тәкъдим итү максатында куллануны сорыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү 152-ФЗ санлы Закон таләпләренә туры китерелеп башкарылуына риза.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгым һәм аны әлеге ризалык бирүдә күрсәтелгән максатларда файдалануга рөхсәтем, мин язмача рәвештә күрсәтмә биргәнгә кадәр чикләнмәгән вакытта гамәлдә.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | _________________ | ______________________________ |
| (дата ) | (имза) | (имзаның расшифровкасы) |